КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Республиканское агентство по печати
и массовым коммуникациям
Декабристов ул., 2, г.Казань, 420066

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ
Республика матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләр агентлыгы
Декабристлар ур., 2, Казан шәһәре, 420066

Тел.: (843)570-31-22, факс:(843)537-91-04, ra.tatmedia@tatar.ru, tatmedia.tatarstan.ru

ПРИКАЗ БОЕРЫК

«03» 10 2022 г. № 155-п

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга (кушымта итеп бирелә).

2. «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә яллаучы вәкиле тарафыннан коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 33-п номерлы боерыкны;

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең 2017 елның 19 июлендәге 33-п номерлы боерыгы белән расланган «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә яллаучы вәкиле тарафыннан коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә бердәнбер башкарма орган буларак түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керергә рөхсәт бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 3 июнендәге 36-п номерлы боерыкны.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары Э.Ф. Әхмәтовага йөкләргә.

Җитәкче А.С.Сәлимгәрәев

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең
2022 елның 3 октябрендәге 155-п номерлы боерыгы белән расланды

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында (алга таба – Агентлык) дәүләт граждан хезмәткәрләре (алга таба – граждан хезмәткәрләре) тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу процедурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип Агентлык җитәкчесе (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – Җитәкче) үзләре өчен яллаучы вәкиле булып торган граждан хезмәткәрләренә кагыла.

Әлеге Тәртип граждан хезмәткәрләренең сәяси партия, һөнәр берлеге, шул исәптән Агентлыкның сайланулы башлангыч һөнәр берлеге оешмасы белән идарә итүдә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәте съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу очракларына кагылмый.

3. Граждан хезмәткәренең коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашуы вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына яисә мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килүгә китермәскә тиеш.

4. Коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтада бәян ителгән рәвештә язмача гариза бирү юлы белән башкарыла.

5. Граждан хезмәткәре гаризаны Агентлыкның коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше буенча җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу гамәлгә ашырыла башлаганчы тапшыра.

6. Җаваплы зат гаризаны кергән көнендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада бәян ителгән рәвештә Журналга теркәп куя.

7. Теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә Җаваплы зат гаризаны карый һәм карау нәтиҗәсе буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны карау барышында Җаваплы зат гариза тапшырган граждан хезмәткәреннән коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә планлаштырыла торган катнашуның функцияләрен төгәлләштерүче аңлатмалар һәм документлар соратып алырга хокуклы.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашырга рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында тәкъдим булырга тиеш.

8. Җаваплы зат гаризаны, бәяләмә һәм башка материаллар (булган очракта) белән бергә, граждан хезмәткәренә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашырга рөхсәт бирү яисә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул итү өчен җитәкчегә тапшыра.

Җитәкче Җаваплы заттан гариза кергән көннән алып ике эш көне эчендә карар кабул итә.

Карар гаризага тиешле резолюция салу юлы белән рәсмиләштерелә.

9. Җаваплы зат җитәкче карар кабул иткәннән соң ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа, кадрлар бүлеге мөһере белән таныкланган имза куйдырып, җитәкче резолюциясе салынган гаризаның күчермәсен тапшыра. Гаризаның төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси делосына беркетелә.

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу тәртибенә
1 нче кушымта

«Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенә

_______________________________________

_______________________________________

(Ф.И.Ат ис., вазыйфа һәм структур бүлекчә,

_______________________________________

яшәү адресы, телефон номеры)

_______________________________________

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу тәртибе турында гариза.

Миңа ____________________________________________________________
(исеме, оештыру-хокукый рәвеше, ИНН, адресы)
___________________________________________________________________

белән идарә итүдә

_______________________________________________________________
(бердәнбер башкарма органы яисә коллегиаль идарә органы исеме)

сыйфатында түләүсез катнашырга рөхсәт бирүегезне сорыйм.

________________ ___________ _______________________________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

«Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу тәртибенә
2 нче кушымта

## «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре тарафыннан коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә түләүсез катнашуга рөхсәт алу турында гаризаларны теркәү журналы

| Т/с | Теркәү датасы | Гариза бирүченең Ф.И.Ат. ис., вазыйфасы | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы зат Ф.И. Ат. ис. | Җаваплы зат имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |